ОКТЯБРЬ 2013
WWW.PROTATARSTAN.RU

# Татарстан

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА




## Министрлар япан кырда

### Бөек күченү булырмы?

**Әгәр сезнең миллионыгыз булса:**
намус белән тапканны ничек арттырырга

**«Халык контроле»:**
миссия үтәләме

**Разил Вәлиев:**
«Адәм баласы ялгызлыкка күреп чумды»

**Владимир Меньшов:**
«Мин үземне үзем тудырдым»

# Зур эшләр кечкенә адымнардан башлана




Бүгенге көндә татар интернетын ясаучыларны балалар белән чагыштырырга мөмкин. Инде күптән нигез салынган булса да, татар интернеты әле дә сабый бала кебек. Интернет челтәренең татар сегменты өчен татар телендә сайт ясаучылар үз интернет-проектларын ясыйлар да үзләренең эш нәтиҗәләрен бәяләп фикер әйтерлек өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк кешене эзли башлыйлар кебек.

Раил Гатауллин тексты

Борчылырлык мәсьәләләр әле күп булса да, хәлне алай ук аяныч дип әйтмәс идем. Татарстан Хөкүмәте бу мәсьәләне аңлый һәм бу юнәлештә «аякка баса» башлады инде. Татар телен үз бизнесын ныгыту өчен файдаланган коммерцияле оешмалар да юк түгел. Microsoft, Билайн, Яндекс, ВКонтакте һ.б. зур компанияләр инде күптән татар телен үстерү һәм шул рәвешле Татарстанда үз позицияләрен ныгыту өстендә эш алып баралар, чөнки сайтның/проектның татар телле версиясен ясау һәм алып бару аларга финанс ягыннан позицияләрен ныгытырга ярдәм итә.

Әлегә күп булмасалар да, татар теленә хөрмәт белән караган күршеләрнең саны арта бара. Ульян, Самара, Чувашия кебек төбәкләрдә татар теле кадердә. Мисал өчен, мәкалә укучыларыбызны Мәскәү өлкәсендәге Дмитров сөт заводы сайты (http://dmz.ru/Tatar/index2.php) белән танышырга чакырам.

Әмма бүгенге көндә татар интернеты әлегә ватанпәрвәр энтузиастлар кулында. Күпләре өйрәнчек дәрәҗәдә ясалган булсалар да, әлеге татар сайтлары үзләренең эчтәлекләре белән кулланучыларны озак вакытка үз сәхифәләреннән чыгармый тотарга сәләтле. Бу сайтлар контентлары белән кыйммәтле дә.

Татар интернетын үстерү өстендә эш алып барган энтузиаст һәм профессиональ веб-осталарны ачыклау, аларны таныту һәм аларга ярдәм күрсәтүне күздә тотып «Белем.ру» ЖЧҖ инициативасы белән 2010 елның февраль аенда дөньякүләм «Белем җәүһәрләре» интернет-проектлар бәйгесе башланып китте. Иң беренче елдан ук ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә 2004-2013 елларга ТР дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча ТР дәүләт программасын үтәү максатында оештырылган әлеге бәйге мәгариф һәм фән, балаларга мәктәптә һәм гаиләдә белем-тәрбия бирү белән бәйле файдалы проектларны ачыклауны максат итеп куйды. Быелгы бәйгене оештыручылар составында ТР Мәдәният министрлыгы белән Татнетны үстерү фонды да бар.

Узган ел бәйгедә 50 гә якын интернет-проект катнашкан булса, быел бәйгедә катнашырга теләк белдергәннәрнең саны 73кә җитте. Бәйгенең нигезләмәсенә туры килгән 68 сайт бәйгедә катнашу хокукына ия булды. Бу юнәлештә АКШтан, Франциядән катнашучы интернет-проектлар булу да шатландыра.

Бәйге нәтиҗәләрен анализлап бары тик сөенергә генә була. Интернет челтәренең татар телендәге сегментында сайтлар саны артып кына калмый, аларның сыйфатлары да яхшыра. Әлеге өлкәдә лидерлар – энтузиаст укытучылар. Мәктәп укучылары һәм студентлар, бу өлкәдә күпкә белемлерәк булуларына карамастан, татар интернеты белән азрак кызыксыналар. Яшьләрне Татнетка тартырдай проектлар, стимул бирә торган бәйгеләр җитми. Кызганычка, Татарстанда

үткәрелә торган күп кенә IT-чараларның (IT-Jump h.б.) татар теленә кагылышы юк дәрәҗәсендә. IT-лицейларда, техник вузларда мәгълүмати технологияләрне рус һәм инглиз телләрендә укытуга кайтып калдык. Дөньякүләм киңлекне яулап алу өчен, алар рус һәм инглиз телләрен якынрак күрәләр, татар теленең дөньякүләм дәрәҗәсен күтәрү әлеге бәйгеләрнең максатларында билгеләнмәгән. Мондый юнәлештә эшне дәвам иткән очракта рус теленең дә кирәге калмас кебек, дөньяга танылу өчен инглиз теле дә җитә.

Ә бит заманында Татарстанда компьютерлар өчен үз операцион системабызны төзү эшләре дә алып барылган, республиканың үз компьютерлары ясалган. Бу турыда әлеге өлкәдә эшләгән Равил Һади кебек «аксакаллар»ыбыз күп мәгълүмат бирә ала. Алар әзерләгән шул ук яшьләр бүгенге көндә бөтен дөньяны яулыйлар, Татарстан яшьләре программалау һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә кайда да беренче урыннарда. Гомумән, 2016 елда информатикадан халыкара олимпиада (!) Казанда үтәчәк бит. Шундый мөмкинлекләр булган очракта ник татар телен танытмаска да, ник әле аны ныгытмаска? Инглиз телендә программалар язган кебек үк татар телендә дә программалар язу да шулай ук гади һәм техника өчен аңлаешлы бит. Бу дөньякүләм танылган факт.




Быелгы бәйгедә катнашырга гариза тапшыру вакыты инде узды, бу мөмкинлекне киләсе ел башыннан файдаланырга мөмкин булачак. Бүгенге көндә IV Бөтендөнья бәйгесенең инде җиңүчеләре дә билгеле, алар белән бәйгенең рәсми сайтында (http://konkurs.belem.ru) танышырга мөмкин. Г.Камал театрында узган тантанада әлеге җиңүчеләрне тантаналы рәвештә бүләкләү уздырылды.

Бәйгедә катнашып җиңеп чыккан сайт авторлары әлеге бәйге һәм татар интернеты турында нинди фикердә торалар?

http://www.lyaysan.ru сайты авторы, 2012 елның «Белем җәүһәре», укучыларын татар сайтларын ясарга өйрәткән Ләйсән Әкбәрова:




**– Ләйсән, узган ел бәйгедә шәхси сайтыгыз белән үзегез җиңсәгез, быел инде укучыларыгыз катнашты һәм уңышларга да иреште. Укучыларыгыз әлеге эшкә күңелләрен биреп тотынганнар идеме?**

– Әйе, минем эшемнең шулай югары бәяләнүе, әлеге конкурста җиңүгә ирешү укучыларыма да бик уңай тәэсир итте. Алар да рухланып, сайт төзү эшенә керештеләр. Укучыларымның бу омтылышлары һәм тәвәккәллеге – минем өчен тагын да зур куаныч булды. Әлбәттә, сайт төзү, аны һәрдаим тулыландырып, яңартып тору җиңел эш түгел. Ул зур тырышлык, белем һәм иҗадилык таләп итә. Укучыларым – Алисә Исхакова һәм Айрат Шакиров бик эзләнүчән, тырыш, сәләтле балалар. Үзләре башлаган эшне һәрвакыт җиренә җиткереп эшләргә тырышалар. Финалга чыгу да алар өчен зур куаныч булды. Хәзер аларның эше башка укучылар өчен дә үрнәк булып тора бит.




http://dilus-19.web-box.ru сайты авторы, 2013 елның «Белем җәүһәре» Дилүс Шәвәлиев:

**– Дилүс, технологияләр өлкәсендә татар телендә сайт ясау башка сайтларга караганда үзенчәлеклерәкме?**

– Информатика укытучысы булуым күпмедер дәрәҗәдә сайт төзүгә зур этәргеч бирде. Татар теле туган телем булганга, бик кызыксынып, шәхси сайтны ана телендә булдыруны мин технологияләр өлкәсенә яңалык кертүгә бер омтылыш дияр идем. Әлбәттә, интернет киңлекләрендә әлеге өлкәдә материаллар рус телендә киң таралыш тапкан. Шунлыктан сайттагы материалларны төрле чыганаклардан җыярга, төрле телләрдән тәрҗемә итәргә туры килде. Үз һөнәреңне яратып башкарганда һәр өлкәнең дә үз үзенчәлекләре бар. Шәхси сайтым һәрвакыт үсештә, һәрвакыт эзләнүдә булырга ярдәм итә. Һөнәремә дә, укыткан фәнемә дә, укучыларыма, алар белән эш алымнарына да башка күзлектән карарга этәргеч бирә.




http://yashel-bishek.ucoz.ru сайты авторы, 2013 елның «Белем җәүһәре» Дилә Мөхәммәди:

**– Дилә ханым, сез төзегән «Туган ягым – яшел бишек» республика программасы инде сайтлы да булган, ул «Белем җәүһәре» исеменә тәкъдим ителде. Әлеге программа турында бераз сөйләп үтегез әле.**

– «Туган ягым – яшел бишек» программасы 2008-2009 уку елында муниципаль заказ буларак 1нче санлы шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сараеның «Нур» милли мәдәниятне һәм сәнгатьне өйрәнү бүлегендә, мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен эшкәртелеп тормышка ашырылды. Программада җыр, бию, шигырь, рәсем һәм башка шундый киң таралган юнәлешләрнең булмавы шарт итеп куелган иде. Бу шартлар үзенә күрә уңайлыклар тудырды.

Табигать чиксез белем чыганагы, без гомеребез буена белемне табигатьтән алабыз. Шуннан чыгып, программаның максаты да балаларда кечкенәдән үк табигатькә мәрхәмәтле караш, туган ягына, туган теленә, яшәгән җирлегенә хөрмәт тәрбияләүгә нигезләнде.

Программаның уңышлы эшләп китүе аның сайтын булдыруга этәргеч булды. Сайт бәйгедә катнашучы балаларның осталыкларын әти-әниләре, якыннары күреп куансын, татар телчеләре, тәрбиячеләр үз хезмәтләрен күреп бәяли алсын өчен эшләнде. Һәм ул шулай булды да. Әйтергә кирәк, чит илдә яшәүче милләттәшләребез дә «Табигать турында бер фикер» дип исемләнгән видеоинтервьюларны бик ошатты.

**« Узган ел бәйгедә 50 гә якын интернет-проект катнашкан булса, быел бәйгедә катнашырга теләк белдергәннәрнең саны 73 кә җитте. Бәйгенең нигезләмәсенә туры килгән 68 сайт бәйгедә катнашу хокукына ия булды.**

http://marsila.org.ru сайты авторы, 2013 елның «Белем җәүһәре» Марсилә Шакирова:




**– Марсилә ханым, мәктәпнең профсоюз оешмасы сайтын булдыру турында фикер ничек туды?**

– Бөтенроссия мәгариф хезмәткәрләренең Үзәк комитеты 2012 елны башлангыч профсоюз оешмасы елы дип игълан иткән иде. Шул уңайдан районыбыз мәгариф хезмәткәрләренең профсоюз оешмасы башлангыч профсоюз оешмаларының сайтларын төзү буенча бәйге игълан итте.

Инде ун елдан артык башлангыч профсоюз оешмасын җитәкләп, тәҗрибә туплаган профсоюз рәисе буларак, мин сайт төзергә булдым. Сайт өчен материаллар тупладым. Үзебезнең башлангыч профсоюз оешмасының эшчәнлеген яктыртуны, яңа эшли башлаган башлангыч профсоюз рәисләренә әз булса да ярдәм итүне максат итеп куйдым

Ә «Белем җәүһәрләре» бәйгесе белән инде мин бәйге башланган көннән үк таныш. Алдагы 2010-2011 елларда мин әлеге бәйгедә «Яшь хәбәрче» түгәрәге сайтым белән катнашкан идем. Быел бәйгегә гариза тапшырганчы озак уйланып йөрдем: язмаларым гел татар телендә генә булмагач, бәйгене оештыручылар тарафыннан кире кагылмасымы? Шуңа күрә башта сайт дизайнындагы рус телендә генә язылган язуларны янәдән татарчалаштырдым. Эшләнгән зур хезмәтем, бәлки, хөкемдарлар тарафыннан уңай бәяләнер дигән өмет белән бәйгегә сайтымны тәкъдим иттем.




http://tarkhanova.ru сайты авторы, бәйгенең иң беренче «Белем җәүһәре», 2013 елның «Җәүһәрләрнең җәүһәре» исемен алучы һәм 2012-2013 елларда бәйгенең жюри әгъзасы булган Гүзәлия Тарханова:

**– Гүзәлия Инсафовна, сайтыгыз бүгенгә кадәр башкаларга үрнәк булып тора, камилләшә һәм ресурсларга байый бара. Быелгы бәйгедә сез сайтларны бәяләүдә дә катнаштыгыз. Узган еллардагылар белән чагыштырганда сайтлар яхшыра барамы?**

– Бәйгегә килгән һәр сайт һәм аны ясаган һәр кеше хөрмәткә лаек. Зур сайтмы яисә кечкенәме, инде берничә ел дәвамында эшләп килә торган сайтмы яисә әле яңа гына ачылганмы – аларның барысы да файдалы эш башкаралар. Сайтлар арасында төрле бәйгеләр оештыручылар үзләре дә зур хөрмәткә лаек. Шундый кешеләрне һәм ресурсларны күреп алу, аларны танытырга тырышу һәм сайтларга игътибар җәлеп итү – бик мөһим эш.

Төрле сайтлар бар. Сыйфаты ягыннан яхшыра барганнары да, туктап калганары да очрый. Авторларны моның өчен гаепләп булмый. Татар интернетында күпчелек сайтлар гап-гади энтузиазмга нигезләнеп барлыкка килгән. Киң җәмәгатьчелеккә файда китерердәй эшлекле сайтларга игътибар ныграк булып, дәүләт дәрәҗәсендә аларга бераз гына булса да финанс ярдәме дә күрсәтелсә, яхшы булыр иде, минемчә. Зур сайтлар беренче кечкенә адымнардан башлана. Шуңа күрә, татар интернетында файдалы проект төзисең килә икән, бер дә куркып торырга кирәкми. Бу эшкә алынырга һәм эшләргә генә кирәк. Татар телен, татар интернетын үстерүгә файда китерә аласың икән, бик хуп. Андый эшләр, хезмәтләр тарихка кереп калачак!

> Ә бит заманында Татарстанда компьютерлар өчен үз операцион системабызны төзү эшләре дә алып барылган, республиканың үз компьютерлары ясалган. Бу турыда әлеге өлкәдә эшләгән Равил Һади кебек «аксакаллар»ыбыз күп мәгълүмат бирә алалар. Алар әзерләгән шул ук яшьләр бүгенге көндә бөтен дөньяны яулыйлар, Татарстан яшьләре программалау һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә кайда да беренче урыннарда. Гомумән, 2016 елда информатикадан халыкара олимпиада (!) Казанда үтәчәк бит.

Конкурста катнашып финалистлар исемлегенә эләгү, интернет челтәренең татар сегментында үрнәк сайт булдыру өчен нишләргә кирәк соң? Иң беренче чиратта, андый сайт уникаль файдалы мәгълүматка ия булырга, технологик яктан камил һәм куллану өчен уңайлы булырга тиеш.




Бу юнәлештә интернет-кулланучылар белән аңлату эшләрен алып баруны үз өстенә Татнетны үстерү фонды алды. Инде бүген Интернет челтәрендә http://tat-i.net адресы буенча фондның рәсми сайты эшләп килә. Сайтта татар интернет-проектларын ясаучылар белән әңгәмәләр, татар интернеты һәм татарча мәгълүмати технологияләр турында аналитик мәкаләләр урын алган. Ни рәвешле компьютерда татар телендә язып аралашырга, ни рәвешле татарча мәгълүмат эзләргә һәм башка күп кенә шундый сорауларга инде бүген үк сайтта җавап табып була.

Фонд сайтының ВКонтакте һәм «Татар иле» социаль челтәрләрендә үз рәсми төркемнәре булдырылды, әлеге төркемнәрдә кулланучылар саны көн саен 40–50 кешегә арта бара. Татар интернеты тормышы белән кызыксынучылар бар, димәк, татар интернетының, татар теленең дә киләчәге бар дигән сүз!